операбыз да үз юлын табар. Мин моңа ышанам. Менә больницага кереп аз-маз сәламәтлегемне «ремонтлап» чыгыйм да, Язучылар союзында тагын бер сөйләшеп карарга туры килер»,— дигән иде.

Язмыштан узмыш юк, күрәсең. Әҗәл, без теләсәк тә, теләмәсәк тә, үзенекен итте, Сибгатне безнең арадан алып китте.

Истәлекләремне Сибгат Хәкимнең үз сүзләренә язган «Авылым минем» исемле җырым белән тәмамлыйсым килә. Мин ул җырны Сибгатнең иҗат бәйрәменә багышлап яздым һәм аны Галиәсгар Камал театрының иске бинасында үткәрелгән тантанада, Миңгол Галиев белән башкарып, шагыйребезгә бүләк иттек.

Авыруыма табиб кирәк түгел,
Йөрәгемнең беләм дәвасын.
Һәр ел саен кайтып иснәп килэм
Авылымның чиста һавасын.

Язар өчен илһам эзлә, диләр,
Урын эзлә, диләр, ямьлерәк.
Никтер минем шигъри хисләремә
Арышларның исе тәмлерәк!

Яннарына барам агайларның,
Фикерләрен ишетеп карарга:
Җырларымда телим гомерем буе
Алар рухы белән янарга.

Истәлек-уйларымны «Барысы да күңелдә...» дип башладым һәм шулай тәмамлыйм да. Бик күп нәрсәләр күңелдә, бик күп... Сибгат Хәким кебек олы җанлы кешеләрнең истәлеге халкыбыз күңелендә озак сакланыр. Сакланыр!

*15 март, 1990 ел.*

Чыганак: Таныш өянкеләр : Сибгат Хәким турында истәлекләр / төз. : М. Вильданова-Хәкимова, Р. Хәкимов. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1996. – 295 б.

*Нури Арсланов*

## ШАГЫЙРЬНЕ ИСКӘ АЛГАНДА

Сибгат Хәкимнең мин аңа хас булган бик күп сыйфатлары белән күз алдыма китерергә тырышам. Менә ул: сабыр-салмак холыклы, тыйнак, уйчан, акыллы, кешеләр белән мөгамәләдә гади, бер вакытта да тавышын күтәреп сөйләшмәс шагыйрь тере килеш каршымда басып тора.



Сибгатне мин күптәннән беләм. Әле Бөек Ватан сугышына кадәр үк шагыйрь Галимҗан Мөхәммәтшин, карикатурачы Зәбих Шәйхуллин, язучы Ибраһим Салаховлар белән бергәләп әңгәмә коруларда минем дә булгалаганым бар. Мондый чакларда мәҗлеснең тамадасы Галимҗан Мөхәммәтшин булып, кичәгә рух биреп утыра торган иде. Без шаркылдап көлешкәндә, Сибгат Хәкимнең бер кырыйда, тыныч кына елмаеп, үзенчә бер тыйнаклык белән утыруын әле дә хәтерлим.

Аннан шактый еллар узды. Мин фин сугышына да барып, әйләнеп кайттым. Сугыштан соң да мин редакцияләрдә рәссам булып эшләгәнгә, ә Сибгат инде танылган шагыйрь буларак нәшриятка һәм Язучылар союзына йөргәнгә күрә Матбугат йортында еш кына очраша идек. Аның өстенә, тагын әдәби кичәләрдә күрешә идек. Аннан Бөек Ватан сугышы да башланып китте. Без фронтта Сибгат белән бер үк юнәлештә булганбыз икән. Ниһаять, сугышлардан да исән кайттык.

Сугыш елларында, яраланып госпитальдә ятканда, мин ике поэма яздым. Шуннан Язучылар союзына да алдылар. Сибгат сугыштан кайтып кулына каләм тоту белән безнең арада иҗади дуслык яңача көчәеп китте. Ул минем әсәрләремә рецензияләр, китапларыма кереш сүзләр язды, юбилейларымда иҗатым турында докладлар белән чыгышлар ясады. Мин аларны, әле күптән түгел генә, яңадан карап, барлап чыктым. Аларда шагыйрь Сибгат Хәкимнең минем хезмәтемә югары бәя бирүе, дусларча иҗади хәерхаһлыгы күренеп тора.

Шулай ук ул миңа үз әсәрләрен дә — тәрҗемәгә булсын, яки рецензиягә булсын — бик ышанып тапшыра иде: әсәрләренә юлга-юл русча тәрҗемәләрне күп эшләдем. Рус шагыйрьләре тарафыннан эшләнгән әдәби тәрҗемәләренә русча рецензияләр яздым. Гомумән, без яшьрәк чакта үзара бигрәк тә якын мөгамәләдә булдык, һәр язган яңа әсәребезне бер-беребезгә укып, фикер алышулар сирәк булмады. Сибгат Хәким мондый чакларда үз әсәре турында әйтелгән фикергә зур игътибар бирә, тирән уйчанлык һәм сабырлык белән тыңлый иде.

Хәтеремдә, бервакыт Сибгат, «Фазыл чишмәсе» җырын язып йөргән чагында, кинәт миннән сорый куйды:

— Арслан (ул миңа гомер буена исемем белән түгел, фамилиям белән эндәште), ялкын түгеләме?

Болай ярдәмче сүзләрдән башка бик үк ачылып җитмәгән бу әйтелеш турында мин уйлана калдым. Ул шунда:

— Суларым түгел, ялкыным түгелде йөрәгемнән, дип әйтеп буламы диюем,— дип кабатлады.

— О, бу инде бөтенләй башка әйбер! Монда йөрәктән ялкын түгелү сурәте бик көчле әйтелә. Әнә бит халык жырында:

«...Керфегеңнән гөлләр тама,

Күрсәң йөрәгең яна»,— диелгән. Керфектән гөл таму да, бер карасаң, сәер күренеш. Ләкин кызның сылулыгын тасвирлап бирү өчен, «күрсәң йөрәгең яна» дигән өстәмә сүзләр ярдәмендә, жырга гаять кирәкле сурәт булып кушылган...

«Фазыл чишмәсе» жырындагы сурәтне халык жырыннан алынган мисал белән «дәлилләп» бирүем ошады булса кирәк, Сибгат Хәким бик канәгать булып елмайды.

Менә бу мисал, кечкенә бер деталь булуга карамастан, сәнгать чараларын куллану башыннан шигърият турында фикер алышуның мөһим һәм зур бер күренеше. Шундый детальләрне еш кулланa алсак, безнең шигъриятебез, һичшиксез, нур өстенә нур булып балкый алыр иде.

«Казан утлары» журналында шигърият бүлеге мөдире булып сигез ел эшләдем. Сибгат Хәким журнал редколлегиясе әгъзасы булганга күрә, күп кенә авторларның әсәрләрен бергәләп карап чыгарга туры килә иде. Бигрәк тә минем фикерләрем белән килешмәгән авторларның кульязмаларын миннән соң Сибгат тикшерә иде. Гажәп, ни гомерләр бергә эшләп тә, безнең арада фикер каршылыклары булмады. Язмаларны китерә, плюс, минус билгеләре белән алдыма куя да:

— Фикерләрең белән килешәм, эшләрлеге барларын эшләсен,— ди иде. Әгәр дә мин берәр сәбәп белән эш урынында булмасам, ул үзенең гадәти эре хәрефләр белән язылган «хөсне хат»ын, кәгазьнең бер почмагыннан икенчесенә диагональ булып төшкән юллар белән сызгалап калдырадыр иде. Миндә ул кадерле язмаларның кайберләре әле дә саклана.

Шигъри әсәрләргә карата фикер бердәге турында тагын бер вакыйганы әйтеп китүне кирәк саныйм. Бусы «Казан утлары»нда эшләгәнгә кадәр үк булган хәл.

Ул замандагы урта буын шагыйрьләрдән берсе (озын гомерле булсын — ул әле дә исән) миңа шигырьләрен китерде. Мин ул чагында «Социалистик Татарстан» газетасында рәссам булып эшли идем һәм, әлбәттә инде, шагыйрь буларак та беркадәр танылган идем. Шулай булмаса, әлеге шагыйрь шигырьләрен күтәреп миңа килмәгән дә булыр иде.



Шигырьләрен укыдым. Әйбәт кенә фикерләре һәм әйтер мәгънәсе булса да, әйтеп житкермәгән икән әле дигән нәтижәгә килдем. Шагыйрь күңелсез генә торды, кәгазьләрен жыеп алды, папкасына салды да чөйдә эленеп торган минем мутон бүрегемә карап:

— Сезнең бүрекләрегез дә бер төсле шул,— диде. Мин гажәпләнеп:

— Кемнең ул — «сезнең»? — дип сорадым.

— Сибгат белән икегезнең,— диде теге.

Юк, ул ачуланмады, көтмәгәндә аерым-аерым ике кешенең фикере, алдан сөйләшкәндәй, уртак булып чыгуы аны ышандырды, әлбәттә. Соңыннан бу хәлне мин Сибгаткә сөйләп көлдердем һәм аның бүрегеннән күземне алмадым; чыннан да безнең бүрекләр нәкъ бер төсле булган икән шул.

Укучылар мине гафу итсен, мин тормышта булган сәеррәк хәлләргә күбрәк игътибар бирүчән кеше инде. Монда да Сибгат Хәким кебек олы шагыйрь турында язганда биегрәк трибунадан торып, олырак фикер йөртү кирәк иде диючеләр булмый калмас. Ләкин кешенең олылыгы аның кечелегендә бит. Кече күңелле олы шагыйрь Сибгат Хәким белән мин әле дә, исән дустым белән сөйләшкәндәгедәй, тәкәллефсез сөйләшәм.

Хәер, ни әйтсәң дә, ничек итеп әйтсәң дә, шагыйрь Сибгат Хәкимнең арабыздан китүе татар әдәбияты өчен гаять зур югалту. Шигъриятебезнең тигез сафларында Сибгат Хәким урыны буш. Ул бушлыкны күп елларга кадәр тоячакбыз... Ул безнең бөек Туфаннарыбыз белән берлектә милли шигъриятебезне озак еллар буена жилкәсендә күтәреп килде. Татар халык шагыйре Сибгат Хәкимнең ижаты әдәбиятыбызның алтын фондында кыйммәтле мирас булып сакланачак.

Сибгат турында әле язылачак, сөйләнәчәк сүзләр күп, алары — киләчәктә. Хәзер мин шушы истәлеккә аның турындагы бер шигыремне дә кушып жибәрәсем килә. Менә ул:

Жыелганбыз Тукай михрабына
Шагыйрьләрнең әллә ничәве.
Шигырь сөючеләр килгән монда,
Сибгат алып бара кичәне.

Шыпырт кына шунда миңа кордаш
Елмайды да мыек астыннан:
— Сөю жырың бу кичәгә бик хас,
Укы әле,— диде,— Арслан.

— Укы әле теге «Кызлар»ыңны,
Бер күңелләр китсен ачылып,
Тыңласыннар әле сызлавыңны
Гүзәлләргә табынып, баш орып.

Сөю моңың чын йөрәктән чыга,
Күренә рухан күккә ашканың!
Синең көчле гыйшкың чынлыгына
Инде мин дә ышана башладым,—

Диде шагыйрь... Ә мин нәрсә әйтим?
Мәхәббәттән анык туймавым.
Ишетә микән әле дә Сибгат Хәким
Лирам хәят җыры уйнавын?..

*Сентябрь, 1986.*

***Гариф Ахунов***

## «ЯШӘ, БОРЧУЛЫ ҖАНЫМ!»

Беренче мәртәбә Сибгат абыйларның өенә 1951 елның май аенда бардым. Ул чакта мин «Совет әдәбияты» журналында әдәби хезмәткәр булып эшли башлаган идем. Университетның дүртенче курсында укый идем әле. Журналның баш редакторы Гази ага Кашшаф мине аларга Шәрәф Мөдәрриснең яңа поэмасын илтер өчен җибәрде. Сибгат абый журналның редколлегия әгъзасы иде. Сибгат Хәким дигән шагыйрьне сугышка кадәрле үк укып белгәнгә, аның «Пар ат», «Шагыйрьнең балачагы» поэмаларын, лирик шигырьләрен бигрәк тә халык яратып җырлый торган җырларын яхшы белгәнгә, мин аларга бик дулкынланып бардым. Беренче мәртәбә якыннан күргәч һәм күрешкәч, ул миндә шактый ук сәер тойгы, гаҗәпсенү тойгысы калдырды. Бәләкәй генә гәүдәле, чандыр, куллары сабыйлар кулы кебек кечкенә. Ә бит ул сугышны узып чыккан кеше. «Бу куллар ничек винтовка күтәрә алды икән?» — дип уйлаган идем. Ул чакта әле Сибгат абый Казан каласының Тукай урамында — уллары Рөстәм һәм Рафаэль, хатыны Мөршидә апа белән — бәләкәй генә квартирда яши иде. Хәтерем ялгышмаса, Мөршидә апаның әнисе дә алар белән иде әле. Хәер, Сибгат Хәкимнең Пушкин урамындагы квартиры да, «Театральная» дигән урамдагы квартиры да зур булмады. Ләкин бу бүлмәләр ничаклы яшь шагыйрьне, прозаикны, тәнкыйтьче һәм галимне авырыксынмыйча кабул итте. Шушы бәләкәй бүлмәләрдә безнең — сугыштан соң әдәбият мәйданына килгән буынның язмышы хәл ителде. Безнең кульъязмаларны ул иренмичә укый, төп-төгәл итеп бәясен бирә иде. Ул Шәүкәт Галиевне, Хисам Камалны, Илдар Юзеевне, Рәшит Гәрәйне әдәбиятка юллады, Равил Фәйзуллиннар буыны да, Мөдәррис Әгъләмовлар да, сиксәненче еллар башында гына күренә башлаган яшьләр дә аның фатихасын алырга өлгерде. Ә бит ул шагыйрьләр белән генә эш йөртмәде. Калын-калын романнар укырга да, аларны журналга яки нәшриятка тәкъдим итәргә дә вакыт таба иде ул. Минем «Яшьлек яме» повестемны, «Хәзинә», «Хуҗалар», «Идел кызы» романнарын матбугатка тапшырды. «Чулпы җыры» драмама махсус җыр текстлары язды, хатлар аша әсәрне ничек көчәйтергә, халык күңеленә ятышлы итәргә икәнен әйтеп, киңәшләрен язып җибәрде. Гомумән, аның хатлары миндә байтак саклана, шагыйрьләрдә тагын да күбрәктер дип уйлыйм. Мин, мәсәлән, аның Әдип Маликов, Саҗидә Сөләйманова, аеруча Гамил Афзал һәм Рафаил Төхфәтуллин белән бик еш хат алышканын беләм. Ул хатларны матбугатта чыгара башларга да вакыттыр инде. Аларда халык шагыйренең тормышка һәм әдәбиятка карашы, дөньяны ничегрәк аңлавы, үз заманына бәя бирүе дә чагылган бит. Минем уйлавымча, андый хатлар (башка шәхесләрнеке дә) «Казан утлары» журналының һәр санында «Әдәби мирас» бүлегендә басыла барырга тиешләр.

Сибгат Хәкимнең портреты минем аңымда нигәдер моңсурак булып калган. Башын түбән иеп, әкрен генә, беркемнең дә күзенә ташланмаслык булып, ул Казан урамнарында йөри иде. Азактан җыр булып киткән бер шигыре бар аның: «Күңелем Ленин белән сөйләшә». Бу сөйләшү халыкча гади һәм халыкча акыллы. Хәзер, бүгенге болгавыр заманда, беркемнең дә кадере калмады, Ленин булып Ленинны тарих чүплегенә ыргытырга теләүчеләр күбәйде. Әгәр исән булса, Сибгат абый Лениннан баш тартмас иде, минемчә. Иртәнге тын сәгатьләрдә, Идел ярында әле порт краннары хәрәкәткә килмәгән, трамвайларның әле беренчеләре генә зыңгылдап узган чакларда, кулларын артка куеп йөрергә, революция даһие белән күңеленнән сөйләшергә, тын гына үз уйларын уйларга ярата иде ул. Уйлары аның республикабыз турында, сугыш давылында үткәргән көннәре турында, мәмләкәтләр өстеннән, океаннарны айкап искән хәвефле җилләр, давыллар турында... Туган халкын, ил буйлап сибелгән якташларын, туган телен һәм, әлбәттә, Тукаен ул беркайчан да исеннән чыгармады. Ленин идеяләренә бәйләп ул Ибраһим Йосфилар, Хисамилар, татар